ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендәге җәмәгатьчелек вәкилләре (алга таба – җәмәгатьчелек вәкилләре) дүрт елга билгеләнеп куелалар.

Бер үк зат җәмәгатьчелек вәкиле итеп берничә тапкыр билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 03 март
№ 2-ТРЗ